12+

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы **28** апрель, **2016** ел № 2 (147)

# Габдулла Тукайга 130 ел!



Бар уем кичен-көндезен
сезнең хакта, милләтем;
Саулыгың – минем саулык,
авыруың – минем авыруым.
Син каршымда бар нәрсәдән
изге һәм хөрмәтле;
Милләт һәм миллиятемне
дөнья бәрабәренә дә сатмам.

*(Г.Тукай «Милләткә» шигыреннән, 1906 ел)*

*Минтимер Шәймиев:*

*Аның шигъриятендә халкыбызның җаны-рухы чагыла, ә милләт рухы, мәгълүм булганча, беркайчан да үлми һәм безнеңнәрдә үләнми. Димәк, Габдулла Тукайның да иҗаты үлемсез һәм иксез-чиксез, ул татар мәдәниятенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән аерылгысыз...*

## • Редактор сүзе



**Ләйлә САБИРОВА**

*Апрель — безгә Тукайны бүләк иткән ай. Шуңа да бөтен татар дөньясы биелгы апрельне Тукай ае буларак билгеләп үтте. Нинди генә чаралар оештырылмады соңгы араларда! Безнең университет та алардан читтә калмады: студентлар көче белән флешмоблар, әдәби кичәләр, фәнни конференция, «түгәрәк өстәл»ләр узды, галимнәребез Тукай иҗаты турында төрле аудиторияләрдә, басма матбугатта, радио-телевидение экраннарында даими чыгыш ясап торды.*

*Гомер юлы шактый кыска булса да, Габдулла Тукай үзеннән соң гаять бай, гаять күпкырлы әдәби һәм публицистик мирас калдырды. Ул — лирик та, сатирик та, заманның иң мөһим социаль-сәяси күренешләрен ачып салган публицист та. Тукайны зурлау — беренче чиратта татарның шигырьгә салынган тирән эчке культурасын, рухын зурлау ул! Бүген шигырь бәйрәмнәре мәктәпләрдән, балалар бакчаларыннан, мәдәният йортларыннан, университетлардан, экраннардан чын мәгънәсендә олы бер ташкын булып урамга чыксын иде, дигән теләктә мин. Шигырь сөйлисе килгән һәркем рәхәтләнеп сөйләсен, Тукай рухын искә алуда үзеннән өлеш кертсен. Бәйрәм билгеле бер вакыт кысаларында үткәрелгән рәсми чара гына булып калмасын иде!*

# ТУКАЙ УЛ БЕРӘҮ ГЕНӘ!

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МУЗЕЕНДА ШАГЫЙРЬ ПРЕМИЯСЕНӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН КАНДИДАТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ КИЧӘСЕ ЕЛ САЕН ОЕШТЫРЫЛА. БУ ПРЕМИЯ 1958 ЕЛНЫҢ 10 нчы АПРЕЛЕНДӘ ТАССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ГАМӘЛГӘ КЕРТЕЛӘ.**

**Ләйсән КАДЫЙРОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Бүген Г.Тукай исемендәге премиягә лаек булган 185 шәхес һәм коллектив бар. Быелгы кичәгә — укучылар белән очрашуга — кандидатлар арасыннан рәссам **Нәҗип Нәккаш**, язучылардан **Вакыйф Нуруллин**, **Фәүзия Бәйрәмова**, **Айдар Хәлим**, **Альберт Хәсәнов**, **Зиннур Хөснияр**, шагыйрьләрдән **Флера Гыйззәтуллина**, **Шәмсия Җиһангирова**, тарихчы-рәссам **Равил Айдаров**, җырчы **Гөлзадә Сафиуллина**, режиссер **Ренат Әюпов** килгән иде. Аларның һәрберсе чыгыш ясады, хезмәтләре белән таныштырды һәм укучыларның сорауларына җавап бирде. Кичәдә кандидатлар татар милләтенең тарихын өйрәнү мөһимлеген, бүгенге җыр сәнгатенең хәлен, мәчетләрдәге бизәкләү элементлары, агач архитектура һәм татар мәдәниятен тудыручы башка күп төрле темаларны яктырттылар. Болар барысы да иҗатчыларны борчыган халкыбызның киләчәге нинди булыр дигән сорауга җавап иде.

Безгә бигрәк тә кандидатларның иреклә аралашуы, яшьләргә мөнәсәбәте ошады. Әлеге кичә замана классикларын берьюлы күрү, иҗатларын күзәтү, чагыштыру өчен дә әһәмиятле булды. Студентлар өчен мондый очрашуларның файдасы бик күп. Танышу кичәсе Айдар Хәлим сүзләре белән тәмамланды: «Әгәр дә минем кулымнан килсә, мин татар халкының һәр кешесенә бер түгел, ун Тукай бүләген биргән булыр идем. Ул аңа лаек». Бәлки бу фикердә, чыннан да, хаклык бардыр. Чөнки күпме авырлыклар, газаплар кичергән баш бирмәс халкым зур хөрмәткә ия. Шулай да милләтебезнең иң күренекле шәхесе исемендәге премияне «иңиң»нәр генә алырга тиеш. Киләчәктә дә бу исемгә дәгъва кылучы мөхтәрәм шәхесләр белән очрашуларны күбрәк үткәрсеннәр иде. Алар вузларга, студентлар янына да ешрак килсеннәр иде, дигән теләктә калам.



Берничә атна дәвамында татар дөньясы яңа геройлар көтеп яшәде! 2016 нчы елда Тукай премиясе кемгә булыр, бу исемгә иң лаек шәхес кем дигән сораулар бөтен Татарстанны кызыксындырды.

26 нчы апрель көнне исә Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы узды. Татарстан Республикасы Президенты **Рөстәм Миңнеханов** имзалаган Указ нигезендә, быелгы Тукай премиясенә лаек булган шәхесләр игълан ителде:

✓**Нәҗип Нәккаш** (Г.Тукай шигырьләре файдаланып эшләнгән шәмаил, ләүхә цикллары, «Ярдәм» һ.б. мәчет дизайны өчен);

✓**Газинур Морат** («Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» китабы өчен);

✓**«Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкларга сузылган юл»** дип аталган экспозицион инсталляция өчен авторлар төркеме.

**Габдулла Тукайга 130 ел**

**27** яшендә вафат була

**10** меңнән артык шигъри юллар яза

**350** хикәя, очерк һәм истәлекләре бар

**26** телгә тәрҗемә ителә



# ТУКАЙ ҮЗЕ ЧАКЫРДЫ

**Рафаэль Хәкимов – сәясәтче, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе:**

*Һәр халыкның үз Тукае бар. Ул – халыкның язмышы хәл ителгән чорда, аңа бөеклеккә юл күрсәтү өчен, күктән җибәрелгән илче. Ул – милләтне ямьсез юклыгыннан яктылыкка, тәрәккъыятькә күтәрүче даһи.*

**Руфинә ДУНАЕВА**

Г.ТУКАЙНЫҢ БӨЕК МИРАСЫ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУЧЫЛАР 13 нче АПРЕЛЬДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНЕҢ ЗУР УКУ ЗАЛЫНДА ШАГЫЙРЬ ЯШӘГӘН ЧОР МОХИТЕНӘ СӘЯХӘТ КЫЛА АЛДЫ.

Китапханә хезмәткәрләре тарафыннан оештырылган әдәби-музыкаль кичә, чыннан да, һәркем өчен XX йөз башы татар тормыш-көнкүрешенә сәфәр кылырга мөмкинлек бирде. Күңел, рух сәфәре иде ул! Юк, уйламагыз, биредә вакыт машинасын тәкъдир итмәделәр, бары тик хыял очышына гына ирек бирелде. Сүз һәм моң-аһәң көче аша.

Кичәнең бөтен үзенчәлеге төп 2 объектка тупланган: беренчесе – Тукай үзе исән вакытта нәшер ителгән китаплар, икенчесе – 1912 елгы граммофон тәлинкәсендәге җыр язмасы. Бәйрәмнең абруйлы кунагы – язучы, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Разил Вәлиев, кичәнең гамен тоеп, дөрес искәртте: «Безне бирегә Тукай үзе чакырды».

Күргәзмәгә бөек шагыйрьнең «Халык моңнары» (1912), «Балалар күңеле» (1911), «Җан азыклары» (1912), «Алтын әтәч» (1909) һ.б. китаплары куелган иде. Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге җитәкчесе Алсу Гәрәева әйтүенчә, Тукайның үзе исән чакта 22 исемдәге 46 китабы нәшер ителгән. Шуларның 14 исемдәгесе Милли китапханә фондларында саклана. Теләгән һәр кеше бу китаплар белән гадәти көндә дә таныша ала икән, хәтта төп нөсхәнең үзен кулга бирәләр.

Санкт-Петербург шәһәрендә 1912 нче елда яздырылган иске патефон тәлинкәсеннән Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин башкаруында Тукайның «Кичке азан» әсәрен яңгырату кичәнең тагын бер истә калырлык мизгеле булды. Әлбәттә, язманың сыйфаты инде таушалган, сүзләре дә аңлашылмый, ләкин хикмәт бөтенләй башкада – чор мохитен шулкадәр нәзакатьле итеп бирә алуын аңлатып булмас аһәң көчендә. Ирексездән, күзләрне йомып, шул вакыттагы Печән базарын, Кабан күле буйларын, Яңа татар бистәсен күз алдына китереп утырасың.

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театры артистларының «Сөй гомерне» дигән шигъри спектакльдән өзек күрсәтүләре, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Илдус Әхмәтҗановның «Без китәбез, сез каласыз» спектакленнән тетрәндерерлек итеп Тукай монологын укуы күңелләрне уятып җибәрде. Чараның ахырында «Туган тел» җырын кумәк башкару исә шагыйрь рухына – дога, милләтебезгә, телебезгә мәдхия булып яңгырады.

---

# #MINEMYARATKANTATARTELEM

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 130 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕННАН «ВКОНТАКТЕ» ҺӘМ INSTAGRAM СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЕНДӘ #MINEMYARATKANTATARTELEM ХЭШТЕГЫ БЕЛӘН ФЛЕШМОБ БАШЛАП ҖИБӘРДЕ.

Флешмобның максаты – яшьләр арасында Габдулла Тукай иҗатына кызыксынуны арттыру, интернетта татар телен популярлаштыру, аның аралашу даирәсен үстерү. Чара «Хәзер Тукай шигырьләре ничек яңгырар иде? Тукай нинди темаларга язар иде? Нәрсәне тәнкыйтьләр иде?» дигән сораулар белән башланды. Катнашучылар сорауларга төрлечә җавап бирә. Күпләр Тукай милләт язмышы турында язар иде дип санаса да, кайберәүләр шагыйрь IT темаларын күтәрер иде дип уйлый. Бер төркем галимнәр исә, Тукай шәхес культы корбаны булыр иде дигән фикердә тора.

Иң мөһиме – Тукайга багышланган чарага Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты **Наилә Фатехова**, Мәскәүнең **«Мәдинә»** рухи ансамбле, Россиянең театр һәм кино артисты **Риналь Мөхәммәтов**, Камал театры актеры, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Тукай премиясе лауреаты **Равил Шәрәфи**, әдип **Рабит Батулла**, КФУның ректор урынбасары **Рияз Минзарипов**, КФУ профессоры **Хатыйп Миңнегулов**, юморист һәм ди-джей **Әбри Хәбриев** һәм башка бик күпләр кушылды.

**Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты:**
Һәр буын шигъърият даһиен яңадан ачып, әсәрләренең геройлары белән бергә борчылып һәм шатланып, замана сорауларына җавап таба. Төрле телләргә тәрҗемә ителгән Тукай китаплары елдан-ел күбрәк басыла, шагыйрьгә яңа һәйкәлләр, аңа багышланган музейлар һәм күргәзмәләр ачыла. Киләчәктә Тукай белән кызыксынучылар саны артыр дип ышанам.



# ТУКАЙ БЕЗНЕ БЕРЛӘШТЕРӘ

**Рәсимә ГАЛИЕВА,** КФУ доценты

ТАТАРСТАН ҖИРЕ ТУКАЙ ИҖАТЫН ДАНЛАГАН ЙӨЗЛӘРЧӘ КУНАКЛАРНЫ КАБУЛ ИТТЕ. КАЗАХСТАН, АМЕРИКА, ИРАН, КАБАРДИН-БАЛКАР, БАШКОРТСТАН, ТАҖИКСТАН, ЧУАШСТАН ҺӘМ БАШКА КҮП ҖИРЛӘРДӘН ШАГЫЙРЬЛӘР, ГАЛИМНӘР, ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ ТАТАРНЫҢ МӘРКӘЗЕНӘ ҖЫЕЛДЫ.




Тукай – бөтен төрки дөньяны берләштергән шагыйрь. 25 нче апрель көнне «Габдулла Тукай һәм төрки дөнья» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциядә бу фикер янә бер кат исбат ителде. Казахстан делегациясе вәкилләре бәйрәм чаралары барышында, бигрәк тә фәнни чыгышларында, Тукайның «казах шагыйре» булуын да билгеләп үттеләр. Халыкара төрки академия гыйльми сәркатибе Шәрип Амантай, балачакта ук «Шүрәле» әкиятен һәм шигырьләрен тыңлап үскәнгә, аны казах дип кабул итүләрен искә төшерде. Казанга килгәнче, Тукайның үсмер чоры, шагыйрь буларак формалашу еллары Уральск (Җаек) шәһәрендә үтә. Ул анда 1895 елдан 1907 елга кадәр яши. Биредә ул белем ала, мәктәп-мәдрәсәдә укый. Соңрак Камил Мотыйгый-Төхфәтуллиннар нәшриятендә хәреф җыючы-наборщик булып эшли. Бу чорда Уральск шәһәрендә чыккан «Уклар» сатира журналы, «Фикер» газетасы һәм «Әлгасрелҗәдит» журналына язышa башлый. Язышу гына түгел, хәтта «Уклар» сатира журналының фактик редакторына әйләнә. Шуңа да Урал якларыннан килүчеләрнең сүзләрендә хаклык бар. Төрекмәнстанның Тел һәм әдәбият институты җитәкчесе Гызылгөл Кыясова да Тукайны төрекмән халкын яңа дәрәҗәгә алып чыгучы дип бәяләде. Бу көнне, гомумән, Тукай белән мәдәниятебез үсте, безне берләштерүче дә Тукай булды, дигән фикерләр күп яңгырады.

Тәрҗемәче һәм язучы Фатих Кутлу шагыйрьнең беренче шигырьләре госманлы төрек телендә язылганлыгын әйтә. «Тукайның татарча да, төрекчә дә иҗат итүе – үзе бер байлык», – ди ул. Ул Тукай язган 130 шигырьнең олуг юбилей мөнәсәбәте илә беренче тапкыр төрекчәгә тәрҗемә ителеп бастырылып чыгарылуы турында хәбәр итте.

Тукай дигәндә, туган телне никадәр камил белү мәсьәләсе дә күтәрелә. Нью-Йоркта яшәгән, бүген Висконсин университетында эшләүче тарихчы галим Юлай Шамил улы Тукай телендә башкаларны көнләштерерлек итеп сөйләшә, фикерләрен җиткерә белә. Ул шагыйрьнең шигырьләрен тарихчы буларак кына түгел, милләте һәм аның теле өчен борчылган шәхес буларак та өйрәнгән.

Тукай иҗатына бәйле яңадан-яңа кызыклы фактлар белән танышырга мөмкин булды. Алар татар галимнәренең «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» китабында бәян ителә. Быелгы фәнни-гамәли конференция барышында да мәгълүмат фонды шактый баеды. Санкт-Петербург шәһәреннән Эльмира Тисенко гаилә ядкарьләре булып сакланган язмаларны Татарстанга алып килгән. «Бу – Тукайның «Мәгариф» нәшрияте җитәкчесе, туганыбыз »





Якубетдин Шәрәповка шигырьләрен бастыру хакында юллаган хаты. Икенчесе – журналист һәм көнчыгыш телләре белгече булган бабам Кәрим Сәгыйтовның Тукайга ярым шаян тонда шигырьләрен тәнкыйтьләп язган язмасы һәм аның Фатих Әмирханның соңгы көннәрен чагылдырган көндәлеге, өченче бүләгебез – Фәйзрахман Әминов иҗат иткән Тукай портреты, шуларны фондка тапшырам», – диде ул.

Тукай мирасын әнә шулай өйрәнү бүген дә дәвам итә. Әле ачыклыйсы, тикшерәсе мәсьәләләр дә шактый күп. Шагыйрьнең 70кә якын псевдонимы, ягъни тәхәллүсе бар икәнлеге исбатланган. Аларны әле өйрәнеп бетерәсе бар. Без әле Тукай иҗатын әнәсеннән җебенә кадәр тикшерелде дип әйтә алмыйбыз. Шуңа да, Мәскәүдә Пушкинны өйрәнү үзәге булган кебек, Казанда Тукайны өйрәнү үзәге булырга тиеш. Аны, һичшиксез, төзергә кирәк.

# БӘЙРӘМ НИЧЕК ҮТТЕ?

**Раил САДРЕТДИНОВ**

26 нчы апрель көнне интеллигенция вәкилләре ТР Президенты **Рөстәм Миңнеханов** белән Тукай һәйкәленә чәчәкләр салды. Анда КФУ ректоры **Илшат Гафуров** та катнашты. Ул Бөтенрәсәй шигырь укучылар бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләде. Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры **Рәдиф Җамалетдинов** билгеләп үткәнчә, бу һәм башка Бөтенрәсәй олимпиадалары нәтиҗәләре буенча университетка керүчеләргә БДИга өстәмә баллар булачак. Димәк, 130 ел үтүгә карамастан, Тукай яшь буында татар теленә, шигърияткә мәхәббәт тәрбияләргә генә түгел, ә Россиянең мәртәбәле университетына юллама алырга да булыша икән.

Казанда бөек шагыйребезнең туган көненә багышлап үткәрелгән чаралар моның белән генә тәмамланмады. Казан яшь тамашачылар театры бинасында Тукайның 1908 елда бирелгән тәүге тапкыр «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын тәкъдим итүен белдергән истәлек тактасы эленде.

Чараларның иң күркәме – Шигърият бәйрәме – көндезге 12дә елдагыча М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры янында урнашкан Тукай һәйкәле янында башланды. Анда, татар шагыйрьләре һәм язучыларыннан кала, Кырым, Тыва Республикаларыннан, чит илләрдән – Әзербайҗан, Иран, Казахстаннан һәм башка бик күп дәүләтләрдән килгән иҗатчылар да катнашты.

Аннан бәйрәм тантанасы театр сәхнәсенә күчте. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов быелгы Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булган шәхесләрне бүләкләде.

Кичә шагыйрьләр, язучылар Г.Тукайның туган җире – Кырлайда җыелдылар, ә бүген, 28 нче апрельдә, татар журналистикасы кафедрасы студентлары тарафыннан Г.Тукайга багышланган шигырь бәйрәме ТР Журналистлар берлегендә үткәреләчәк.

*Равил Фәйзуллин:*

*Яздан аерып булмый*
*Тукайны!*
*Язда килгән,*
*язда янган ул.*
*Язы, киләчәге*
*барлар ничек*
*китсен,*
*Ничек югалалсын*
*дөньядан.*

*Кемнәр көтми*
*ышанулар, гөлләр,*
*Яшәүләр биргән*
*бу айны?*
*Яздан, гаделлектән,*
*киләчәктән*
*Мөмкин түгел аеру*
*Тукайны!*



**Фатих Кутлу, тәрҗемәче һәм язучы:**
Тукайның көйгә салынган шигырьләреннән аудиоҗыентык әзерләргә кирәк. Мәктәп укучыларына тарату бер файда булса, аны сатуга чыгару – икенче файда: килгән кунакларга да, читтә яшәүче татарларга да менә дигән бүләк булачак.

*Рәсүл Гамзатов – авар шагыйре:*
*Тукайны үз халкының ут сакчысы дип атарга була. Бу – мәхәббәт уты, талант уты, бу – бозыклык, ялган белән килешмәү уты, бөтен дөньяның күпсанлы дошманнарына нәфрәт уты. Бу утны ул безгә мирас итеп калдырды.*

17 нче АПРЕЛЬ КӨННЕ КАЗАНЫБЫЗДА «ТАТАР-ДОЗОР» КВЕСТ-УЕНЫ УЗДЫ. ӘЛЕГЕ ЧАРАНЫҢ МАКСАТЫ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ИКЕТЕЛЛЕЛЕК ТУРЫНДАГЫ ЗАКОННЫҢ ҮТӘЛҮ-ҮТӘЛМӘВЕН КҮЗӘТҮ, МИЛЛИ МИРАСНЫ САКЛАУ, ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ДАИРӘСЕН КИҢӘЙТҮ, УКУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ СТУДЕНТЛАРНЫҢ ИҖАДИЛЫГЫН АРТТЫРУ.

**Алия МАССАРОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



# КАЗАН ҮЗӘГЕНДӘ – ТЕРЕ Ә ХӘРЕФЕ

Быел мәктәп укучылары гына түгел, югары уку йортлары студентларына да квестта катнашу мөмкинлеге бирелде. Бу чарада төрле вузлардан катнашырга теләк белдерүчеләр күп булуы сөенечле. КФУның Л.Н.Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтыннан хәтта 3 команда тупланды! Тулаем алганда, Казанның һәм Татарстанның гомуми һәм профессиональ белем бирү, югары уку йортларыннан 45 гариза кабул ителде, шуның 31е сайлау турын үтте. Узган ел белән чагыштырганда, бу ике тапкыр күбрәк!

Маҗаралы уен быел сигезенче тапкыр үткәрелде. Өч йөздән артык кеше, командаларга бүленеп, алдан билгеләнгән маршрут буенча



йөреп, урамда, сәүдә нокталарында һәм кафеларда татар теленең кулланылыш дәрәҗәсен тикшерде. Командалар, Казанның тарихи урыннарын үтеп, төрле иҗади биремнәр башкарды, мәсәлән: флешмоб – шәһәрнең тарихына кагылышлы табышмакларга җавап бирү, биремнәргә махсус туры китереп, фото һәм видео төшерү, аны Instagramга кую һ.б.

Һәр пункттагы бирем Казан тарихы һәм татар әдәбияты белән бәйле иде. Катнашучылар «Гыйлем» фәнни-популяр медиа-проекты тарафыннан оештырылган бәйгедә фәнни терминнарны татар теленә тәрҗемә итте. Шулай ук арт-перфоманс оештыру, кинофильмга сценарий язу, «Билайн» компаниясе оештырган конкурста катнашу, күренекле татар эшлеклеләре яшәгән урыннар белән танышу мөмкин иде. Ә иң мөһиме, һәркем Бауман урамында уздырылган киң масштаблы флешмобта – «тере» зур «Ә» хәрефен ясауда катнашты.

«Татар-дозор» квест-уены җиңүчеләре Г.Тукайның туган көнендә игълан ителде.

---

КАЗАННЫҢ БАУМАН УРАМЫНДА БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ ТАРАФЫННАН ОЕШТЫРЫЛГАН «МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ» АКЦИЯСЕНЕҢ ГАЛА-КОНЦЕРТЫ ГӨРЛӘП УЗДЫ.

**Эльвира ГАЙНЕТДИНОВА**




Яшь архитекторларның урам күргәзмәсендә төрле бәйгеләрдә Россия регионнарыннан да кунаклар – Башкортстан, Марий-Эл һәм Удмуртия республикасы, Саратов, Ульяновск һәм Киров өлкәләреннән һ.б. шәһәрләрдән актив яшьләр акциядә теләп катнашты.

Акциянең музыкаль бизәлеше буларак, лейбл Yummy Musicтан **K-Ru&Ittifaq, Илгиз Шәйхразиев, Оскар&C7C5, Рәдиф Кашапов, Зарина Вилданова** һ.б. булды. Тере музыка конкурсы да үткәрелгән иде. Аның нәтиҗәләре буенча үз тамашачысын табарга өлгергән «ALTAN» һәм «Yellow Side» рэп-төркемнәре, Эльнар Байназаров, «Асылташ», «Baradj» һәм «Juna» төркемнәре дә танылган җырчылар белән бергәтән чыгыш ясады. Моннан тыш, татар фольклорына һәм заманча бию электрон музыкасына үзенең мәхәббәте белән аерылып торучы «Tatarsis» үз проектын тәкъдим итте. Әлеге проектның авторы, идеологы, композитор – **Радик Сәлимов**. Ул заманча академик жанрларда иҗат ителгән, республикабызның алдынгы коллективлары һәм башкаручылары өчен музыкаль әсәрләр авторы.

Мәскәү шәһәреннән «Шүрәле» татар этно-поп-рок төркеме дә чыгыш ясады. Аларның музыкасыннан ташып торган позитив энергия өметне беркайчан да югалтмаска, алга һәм бары тик алга гына атларга өнди. Иң мөһиме – татар яшьләренең заманча, кыю фикерләүләре сөендерә.

# JADIDFEST

**АПРЕЛЬ БАШЫНДА БАШКАЛАДА ТАТАР ДИЗАЙНЫН ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫН ЯКТЫРТУЧЫ JADIDFEST ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫ.**

**Регина ШИҺАБЕТДИНОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты



Чараның исемен Бөтендөнья татар яшьләре форумы вәкиле **Радиф Кашапов** уйлап тапкан. Җәдидләр — ул яңалык кертүчеләр. Татар мәдәнияте дә бер урында басып торырга тиеш түгел, дип саный ул.

JADIDFESTның максаты — татар дизайнерларының иҗат җимешләрен халыкка җиткерү, заманча шәһәр татар мәдәниятен үстерү.

***Нажия Галимова** (Najiya Galimova брендына нигез салучы):* «Минем шөгылем — ул йөрәк эше. Тукыма сайлаудан башлап, соңгы бизәккә кадәр шәхесне күз алдында тотып иҗат итәм. Кул эшләренә ихтыяҗ булды, бар һәм булачак. Үзем һәрвакыт акча өчен генә эшләмим, кайвакыт кемгәдер бары тик ярдәм кулы сузарга гына да кирәк була. Кешене илһамландыра торган әйберләр иҗат итәсе килә».

Татар дизайнерлары арасында Европага юл салучылар да бар. Андыйларның берсе – ***Мира Рәхмәт** (Mira Rakhmat бренды башлыгы):* «7 ел элек берәр оригиналь нәрсә булдыру бизнес-идеясе туды. Татар мәдәнияте – минем туган мәдәният, шуңа аның белән шөгыльләнергә булдым. Соңрак бу нәкъ минем юл икәнен аңладым. Проектым узган елны «Печән базары»нда балкыды. Быел исә үземнең исем астында концепт-бюро ачтым. Иҗатымның йөзе – чигүле бизәк. Ләкин ул һәрбер киемдә бар дигән сүз түгел: гади киемдә аны кулллансам, милли стильдәге киемдә ул инде артык. Сораучылар күп, дөресен әйтим, хәзер җитештерүчеләр инде өлгерми».

***Батыр Харисов,** «BAL-DAN» продукциясен тәкъдим итүче:* «Безнең бабайлар — умартачылар. Без — крем-бал җитештерүче бренд. Продукция бары тик дәүләт таләпләренә туры килгән балдан гына ясала. Без сыйфат ягында! Туристлар өчен махсус Татарстан балы җыелмаларын тәкъдим итәбез».

Чарада нәниләргә дә зур игътибар бирелде. Бала кризислары һәм алар белән ничек көрәшергә?! Әлеге темага үзенең киңәшләре белән балалар психологы ***Тәслия Муллагалиева*** уртаклашты.

**«Калеб»** яңа буын җыены «Такташнон-стоп» арт-перфомансын үткәрде. Өч сәгать буена сәхнәдән шигырьләр яңгырап торды. Аларны танылган шагыйрьләр, музыкантлар, журналистлар, артистлар һәм катнашырга теләк белдергән һәркем сөйләде.

***Владимир Гордлевский – СССР Фәннәр академиясе әгъзасы:***

*Тукай туүы – милли горурлык, Тукай үлеме – милли кайгы. Тукай белән халык арасында өзелмәс элемтә сузылган. Тукай үзенә халыктан алганны аңа өчләтә кайтарды.*

**«Darelfənyn» газетасының он-лайн версиясен (http://darelfonyn.kpfu.ru) укыгыз**

## БЕРДӘМ ДИКТАНТ ЯЗУ

Татар телен саклау, үстерү теләге белән янып йөрүчеләр башка уку йортларында да күп икән. Казан дәүләт медицина университеты Тукайның туган көне уңаеннан Габдрахман Әбсәләмовның «Ак чәчәкләр» әсәре буенча Бердәм диктант язу мөмкинлеге булдырды.



## ДӨНЬЯКҮЛӘМ I ОНЛАЙН КОНТРОЛЬ ЭШ

КФУның ИТИС Югары мәктәбе студентлары, Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты интернет челтәрләрендә Тукай иҗаты буенча Дөньякүләм I онлайн контроль эш эшләргә тәкъдим иттеләр.







Әстерханда 1911 елның җәендә төшкән фоторәсемдә Габдулла Тукай,Сәгыйть Рәмиев,Шаһит Гайфи. Тукай Әстерханга баргач, Шаһит Гайфи анда аның яшәешен кайгыртучы була. Тукайны күп тапкырлар кымыз эчәргә алып баралар. Әстерханда Тукай шифаханә шартларында яши.

Г.Тукайның Уральскидагы матбагада эшләгән вакытында төшкән фоторәсеме. 1905 ел.



Г.Тукайның дусты Ф.Әмирхан, Г.Коләхмәтов,К.Коләхмәтов белән төшкән 1912 елгы фоторәсеме.

# Син Тукайны беләсеңме?

**Раил САДРЕТДИНОВ**

**ҺӘР ЕЛНЫ АПРЕЛЬ ҖИТТЕМЕ, ТОРМЫШЫБЫЗДА ҮЗГӘ БЕР ҖАНЛАНУ – Г.ТУКАЙНЫҢ ТУГАН КӨНЕНӘ ӘЗЕРЛӘНҮ, АНЫ ҮТКӘРҮ МӘШӘКАТЕ БАРЛЫККА КИЛӘ.**



Тормышыбызны, милләтебезне Тукайдан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Халкыбыз үз шагыйрен онытмый. Монысы — күңелне иң сөендергәне. Тукай да сөенәдер, мөгаен. Без дә укучыларыбызның, яшьләрнең ни дәрәҗәдә Тукайны белүләрен тикшереп карарга булдык. Моның өчен аларга: «Синеңчә Тукай кем ул?», «Тукай диюгә, күз алдыңа нәрсә килә?» дигән сорауларны бирдек, Тукай турында истә калган фактларны санап чыгуларын үтендек.

■ **Алинә Зиннурова, КФУ Бутлеров ис. Химия институтының 3 нче курс студенты:** Минемчә,Тукай — татар халкының энҗе-мәрҗәне, бөек шагыйрь! Бик аз гына гомере эчендә дә бик күп шигырь-хикәяләр язган, безне Шүрәле, Су аналары белән таныштырган, үзеннән соң зур эз калдырган, күңелләрдә мәңге яз булып калган олуг шәхес ул! Тукай диюгә, яз, апрель ае, Тукай һәйкәле искә төшә, тормыш тарафыннан нык кыерсытылган кечкенә Апуш, инде яшь шагыйрь булган Тукай күз алдына килә, аның «Исемдә калганнар»ы, «Туган авыл»ы хәтердә яңара.

■ **Айзирәк Садыйков, Биология һәм фундаменталь медицина институтының 3 нче курс студенты:** Кечкенәдән тормышның ачысын татып үскән, аның сынауларына нык торган, безнең өчен үрнәк булган кеше ул Тукай. Ул — күренекле даһиебыз! Тукай сүзен ишетүгә, күз алдына мәңге яшь калган шагыйрь килеп баса, бер мизгелдә хәтеребездә аның бар тормыш юлы яңара. Урманда кеше кытыклап йөрүче Шүрәле, алтын тараклы Су анасы һәм башка зур мәгънәгә ия булган шигырь-әкиятләрен дә искә төшерми мөмкин түгел.

■ **Айсылу Гаффарова, КФУ Инженер институтының 4 нче курс студенты:**
Мәктәптә өйрәнгәннәрдән Тукайның ятим бала булып үсүе, онытылмас шагыйрь, 27 яшендә авырып вафат булуы истә калган. Тукай диюгә, күз алдыма «Су анасы», «Шүрәле», «Исемдә калганнар» дигән китаплар тышындагы кечкенә малай һәм мәктәптә, сыйныф почмагында эленгән тирән карашлы Тукай портреты килеп баса, «Туган тел», «Пар ат», «Эш беткәч уйнарга ярый» дигән шигырьләре искә төшә.

■ **Зилә Хаҗипова, КФУ Лобачевский исемендәге лицейның 10 нчы сыйныф укучысы:** Аның Кушлавыч авылында туганлыгын, Кырлайда үсүен, Крылов мәсәлләрен тәрҗемә итүен беләм. Тукай дигәндә, мин Шүрәле, Су анасын күз алдына китерәм. Әлбәттә, аның танылган фотосын, «Туган тел» шигырен искә төшерәм. «Бабай», «Бичара куян», «Безнең гаилә», «Туган авыл», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Кошчык» «Шаян песи» — болары минем яраткан шигырьләрем.

***P.S:*** Сораштыруда катнашкан һәрбер яшь кешенең авызыннан «Су анасы» һәм «Шүрәле» әкиятләре ишетелде, димәк, балалар бакчасында алган милли белем һәм тәрбия гомерлеккә күңелгә сеңеп кала икән.

DARELFØNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Дунаева, А.А.Абдрахманова, Р.Р.Садретдинов
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Битеә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 27.04.2016. «КАРТИ» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание, 100.